2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы җирлеге Клементейкино авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

12 ноябрь 2022 ел

№ 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең Клементейкино авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең Клементейкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Клементейкино авылы, Үзәк урамы, 38 А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Клементейкино авыл җирлеге башлыгы Л.Э. Языков